ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10 гыйнвар 2025ел № 14

Башкарма комитетның 2022 елның 4 августындагы 3942 номерлы Карары белән расланган муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану шартнамәсе төзү хокукына сатулар нәтиҗәләре буенча мондый шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2022 елның 4 августындагы 3942 номерлы Карары белән (Башкарма комитетның 2023 елның 2 июнендәге 4676 номерлы Карары редакциясендә) расланган муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану шартнамәсе төзү хокукына сатулар нәтиҗәләре буенча мондый шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 бүлектә «2.16.1» цифрларын «2.15.1» цифрларына алмаштырырга;

2) 2.15.1 пунктның 2 пунктчасында «Республика порталы» сүзләреннән соң «, Бердәм портал» сүзләрен өстәргә;

3) 2.15.3 пунктның 5 пунктчасында «Республика порталы» сүзләреннән соң «, Бердәм портал» сүзләрен өстәргә;

4) 3.7.1 пунктның бишенче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«гариза бирүчегә (аның вәкиленә) Бердәм, Республика порталы аша электрон хезмәттәшлек ярдәмендә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен КФҮдә алу мөмкинлеге турында хәбәр итә.»;

5) 4 нче кушымтаны әлеге карарга кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2025 елның 10 гыйнварындагы
14 номерлы карарына
кушымта

«Муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану шартнамәсе төзү хокукына сатулар нәтиҗәләре буенча мондый шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
4 нче кушымта

Форма

Кемгә (җирле үзидарә органының исеме)
_______________________________________________
_______________________________________________

ГАРИЗА

Мәйданы _______ кв.м булган, _________________________________________ адресы
(*объектның адресы*)
буенча урнашкан бинаның _________ этажындагы торак булмаган бинаны (мөлкәтне) ______________________________________________________________________________
(*бинаның, мөлкәтнең төре күрсәтелә*)*
_____________________________________________________________ үткәрү (урнаштыру) өчен
(*бинадан файдалану максаты күрсәтелә*)
_______________________________________________ түләүсез файдалануга бирүне сорыйм.
(*оешманың – Ссуда алучының исеме*)

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирүне сорыйм:

☐ Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының шәхси кабинетына;

☐ Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының шәхси кабинетына;

☐ Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә;

☐ Башкарма комитетта.

_______________ __________________ ( __________________)
(дата) (имза) (Ф.И.А.и.)»

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева